| УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ |
|---|---|---|

| **ПРИКАЗ** | | **БОЕРЫК** |
|---|---|---|
| 23.03.2016 | Казан шәһәре | 01-05/75-пр |

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсендә дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерүе мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килү турында хәбәр итүләре тәртибен раслау турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның һәм бүтән затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерүе мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килү турында хәбәр итүләре тәртибе хакында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 22 декабрендәге 650 номерлы Указы нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсендә дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерүе мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килү турында хәбәр итүләре тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.
2. Оештыру-хокукый эш бүлеге башлыгы (Аблеева Л.М.) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынуын;

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсендә дәүләт граждан хезмәткәрләрен, шулай ук

гражданнарны алар хезмәт контрактлары төзегәндә әлеге боерык белән таныштыруны;

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең «Коррупциягә каршы сәясәт» мәгълүмат стендына Тәртипне урнаштыруны.

3. Күзәтчелек һәм автоматлаштырылган исәпкә алу бүлеге (Хәйруллин Р.Ф.) әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе сайтындагы «Коррупциягә каршы тору» бүлегендә урнаштырырга тиеш.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Вакытлыча башлык вазыйфаларын башкаручы М.А. Халиков

Татарстан Республикасы
Үзйөрешле машиналар һәм
башка төр техниканың техник
торышына күзәтчелек идарәсенең
23.03.2016 № 01-05/75-пр
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсендә дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерүе мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килү турында хәбәр итүләре тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсендә дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – граждан хезмәткәрләре, Идарә), эшкә яллаучы вәкиленең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерүе мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килү турында хәбәр итүләре процедурасын регламентлый.

2. Хәбәр итү вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерүе мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында әлеге Тәртип кушымтасында китерелгән форма буенча граждан хезмәткәре тарафыннан язма рәвештә төзелә (алга таба – хәбәрнамә) һәм башлыкка җибәрелә.

3. Башлык өч эш көне эчендә алдан карау өчен хәбәрнамәне коррупцион һәм бүтән хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка (алга таба – җаваплы зат) җибәрә.

4. Хәбәрнамәне алдан карау барышында җаваплы зат хәбәрнамә җибәргән граждан хезмәткәреннән анда бәян ителгән хәлләр буенча аңлатмалар алырга, дәүләт хакимияте органнарына, бүтән дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга билгеләнгән тәртиптә гарызнамәләр җибәрүне кузгатырга хокуклы.

5. Алдан карау нәтиҗәләре буенча җаваплы зат дәлилләнгән бәяләмә әзерли. Алдан карау барышында алынган хәбәрнамә, бәяләмә һәм материаллар җаваплы зат тарафыннан алынган көненнән соң җиде эш көне эчендә Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе рәисенә (алга таба –Комиссия) тапшырыла.

6. Әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән гарызнамәләр җибәрелгән очракта, хәбәрнамә, бәяләмә һәм материаллар җаваплы зат тарафыннан хәбәрнамә алынган көннән соң 45 көн эчендә Комиссия рәисенә тапшырыла. Күрсәтелгән срок Комиссия рәисе тарафыннан 30 көннән дә артмаган чорга озайтылырга мөмкин.

7. Хәбәрнамә, бәяләмә һәм материаллар Комиссия тарафыннан Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында 23.06.2015 № 01-05/100-пр боерыгы белән (Идарәнең 12.02.2016 № 01-05/42-пр боерыгы белән кертелгән үзгәрешләре белән) расланган нигезләмә нигезендә карала.

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсендә дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерүе мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килү турында хәбәр итүләре тәртибенә
кушымта

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе башлыгы
Р.Р. Зыятдиновка

___________________________________________
___________________________________________
___________________________________________
(Ф. Ис. Ат. ис., биләгән вазыйфасы)

Вазыйфаи бурычларын үтәгәндә
мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерүе мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килү турында
хәбәрнамә

Дәүләт вазыйфаларын үтәгәндә минем мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуым барлыкка килү турында хәбәр итәм (кирәгенең астына сызарга).

Шәхси кызыксыну барлыкка килү өчен нигез булган хәлләр:
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
__________________________________________________________

Үтәлүләре барышында шәхси кызыксыну йогынты ясый торган һәм йогынты ясарга мөмкин булган вазыйфаи бурычлар:
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу яисә җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар:

______________________________________________________________________________
_________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
________________________________________________________________

Әлеге хәбәрнамәне караганда Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга ниятлим/ниятләмим (кирәгенең астына сызарга).

«____» ________201___ел _______________________ _________________________
(датасы) (имзасы) (имзасы расшифровкасы)